Алтын җирдән табыла , белем – китаптан.

# Белем чишмәсе

**октябрь, 2020 ел**

## Мәктәп яңалыклары

Җәй үтеп, көз җиткәч үк, нәкъ Нәҗип Думави әйткәнчә, “ мәктәп күзен ача, җанлана”.

Сентябрь ае, мавыктыргыч һәм дә берсеннән берсе катлаулы дәресләр уку белән беррәтән, төрле кызыклы чараларда катнашып, сизелми дә үтеп китте.


3 нче октябрь - Татарстан Варислары берлегенең туган көне уңаеннан табигатькә экскурсиягә чыктык. Күңелле ял иттек. Спорт уеннары уйнадык.

*Эзтабар һәм варисларның буш вакыты һич булмас. Спортта, хезмәттә алар беркемгә дә оттырмас.*



***************

7сыйныф укучылары “Үсеш ноктасы” цифрлы һәм гуманитар юнәлешле белем бирү үзәге булган Тымытык авылы мәктәбенә бардылар.



## Укытучылар көне белән!



Һәр кешенең “Менә ул чын укытучы”, — диярлек остазы бар. Ул аны еллар узгач саен сагынып искә ала, гомере буена рәхмәт укый. Укытучы беренче тапкыр мәктәпкә килгәч, хәреф танырга, язарга өйрәтә. Үзе белән белем дөньясына алып керә. Аның белән дөньяның төрле баскычлары буенча югарыга күтәреләсен, тормышны күрергә, танып белергә өйрәнәсең.

Хөрмәтле укытучыларыбыз! Сез биргән белемнәр, сезнең үгет-нәсихәтләрегез тормышта дөрес юлдан тайпылмыйча, гел алга барырга ярдәм итә. Үзегезгә дә укучыларыгызның рәхмәтләренә төренеп, аларның ярдәмен тоеп яшәргә насыйп булсын. Атачак таңнарыгыз – аяз, туасы көннәрегез – кояшлы, төннәрегез – тыныч, сәламәтлегегез нык булсын!



## Абдулла Алишның туган көне

Язучы да Алиш, батыр да,
Яуда яшен кебек яшьнәгән!
Ил алдында тик бер тапкыр да,
“Мин батыр” дип гайрәт чәчмәгән.

15 нче сентябрьдә балалар язучысы Абдулла Алишның тууына 112 ел булды.

Фашист тоткынлыгында, төрмәдә ятканда, танылган балалар язучысы Абдулла Алиш туган иленә кайтып, аның саф һавасын сулау хакында хыялланган. Ләкин аның бу хыялы тормышка ашмый калган...

Әмма иле турында уйлаган-нарның гомере озын була бит. Менә Алиш , бер гасыр узганнан соң, туган ягына кайтты. Һәйкәл булып, җыр булып, хәтер булып.



Үзем турында җыр

Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем: кирәк түгел, дип,
Кайтам мин, дип, туган илемә.
Әйтсәләр дә: алтын сарайда тор син,
Ләкин илең ирексез калсын, дип,
Әйтер идем: мине зинданга сал,
Фәкать илем ирекле булсын, дип.
Ничек тели җаның, шулай яшә,
Кара кашлы кызлар үзеңә,
Дисәләр дә, әйтер идем: кирәк түгел,
Кайтам мин, дип, зәңгәр күземә.
Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер ватанын.

А.Алиш

# Юлларда сак булыгыз!



Көн саен, телибезме без моны юкмы, без барыбыз да бик мөһим рольне башкарабыз – җәяү йөрүче ролен. Аның белән безнең сәламәтлегебез, хәтта тормышыбыз да бәйле. Юл-транспорт хәлакәтләренең 25 %-ты җәяүлеләрнең юл йөрү кагыйдәләрен каты бозу белән бәйле.

**Җәяүлеләр йөрергә тиешле урыннар:**

- тротуар; юл кырые; җәяүлеләр өчен сукмак;

-велосипедта йөрү өчен юллар.

- шәһәрдән яки авылдан чыккач, җәяү йөрүчеләр транспортка каршы барырга тиеш, ә шәһәр, яки авыл эчендә — каршы һәм транспорт йөреше буенча.

- велосипедны, мопедны, мотоциклны, чаналарны, кул арбаларын алып баручы, инвалид коляскаларда баручы кешеләр транспорт йөреше буенча барырга тиеш.

Безнең мәктәптә оешкан “Светофор” түгәрәгенә йөрүчеләр юлда йөргәндә хәвефсезлекне кисәтү максатыннан аңлату эшләре алып баралар.Сентябрьдә “Мин куркынычсыз маршруттан гына йөрим”, “Безопасный переход” акциясе уздырылды.Юл кагыйдәләрен белү буенча “Уен-викторина”да 4 сыйныф укучылары бик теләп катнашты. Урамда куркыныч урыннар билгеләнде. Велосипедта йөрү кагыйдәләрен өйрәнүне дәвам иттәләр.



***********



Коронавирус дигән мәкерле чирдән саклану өчен гигиенаның гади кагыйдәләрен үтәү дә ярдәм итә.

- Иң төп кагыйдә, әлбәттә – кулларны сабын белән еш юарга. Дезинфекция чарасын куллану да ярдәм итә.

- Үзең белән спиртлы яки вируслардан зарарсызландыра торган салфеткалар йөртергә тырышыгыз. Кулны юу мөмкинлеге булмаганда шулар бик ярап кала.

- Юылмаган куллар белән күзләргә, иренгә, борынга кагылмаска тырышыгыз.

- Коронавирус вакытында кул бирешми, баш кагып сәламләшү дә җитә.

- Ютәллләгәндә, төчкергәндә авыз, борынны бер тапкыр кулланыла торган салфкеткалар белән каплагыз һәм соңыннан чүплеккә ыргытыгыз.

- Мәктәптә һәм өйдә өстәл өсләрен, ишек тоткаларын, телефоннарны һәм техникаларны чистартып торырга кирәк.

- Җәмәгать урыннарына чыкканда, авыруны караганда медицина битлеге кию мөһим. Ә урамда кимәсәң дә була, ди табиблар.

- Ютәллләгән, төчкергән кешедән ераграк торырга кирәк. Ким дигәндә 1 метр ераграк тору хәерле. Чөнки вирус һава-тамчы юлы белән күчә.

- Үзегезне начар хис итәсез икән яки шик-шөбһә булса, иң яхшысы – өйдә калырга һәм табиб чакыртырга. Үзебезне һәм якыннарыбызны саклыйк! Сәламәт булыйк!

# Татар баласы укырга тиешле 100 китап

**Башлангыч сыйныф укучылары өчен**

1. Абдулла Алиш. Ана әкиятләре.
2. Резеда Вәлиева. Нәниләр китабы / Ак песи (җыентыклар).
3. Шәүкәт Галиев. Шәвәли хәйләсе : шаян шигырьләр.
4. Галимҗан Гыйльманов. Әбием сихерче бугай (җыентык).
5. Рафис Корбан. Тапкырларга табышмак (җыентык).
6. Рөстәм Мингалим. Галстуклы кәҗә (җыентык).
7. Роберт Миңнуллин. Сөенсеннәр әле сабыйлар (җыентык).
8. Хәкимҗан Халиков. Иң гадел дус (җыентык).
9. Халык иҗаты: әкиятләр.
10. Халык иҗаты: мәкальләр һәм әйтемнәр.
11. Халык иҗаты: табышмаклар.

**Урта сыйныф укучылары өчен**

12. Гамил Афзал. Рәхмәт (җыентык).
13. Мирсәй Әмир. Миңнекамал.
14. Фатих Әмирхан. Ай өстендә Зөһрә кыз.
15. Габдрахман Әпсәләмов. Алтын йолдыз.
16. Фәүзия Бәйрәмова. Кыңгырау / Алыплар илендә
17. Ибраһим Гази. Тургай картаямы икән?
18. Мәҗит Гафури. Шигырьләр / Кара йөзләр.
19. Нәбирә Гыйматдинова. Сихерче / Сәвилә.
20. Дәрдемәнд. Агарган кыл (җыентык)
21. Нәҗип Думави. Су кызы / Болгар кызы Тойгы туташ.
22. Әмирхан Еники. Тауларга карап / Уяну.
23. Нәкый Исәнбәт. Хуҗа Насретдин.
24. Ләбибә Ихсанова. Тузганак (хикәяләр җыентыгы)
25. Галиәсгар Камал. Безнең шәһәрнең серләре.
26. Фатих Кәрим. Поэмалар.
27. Ләбиб Лерон. Чыктым аркылы күпер (җыентык).
28. Шәйхи Маннур. Поэмалар / Чын сөю бармы?
29. Каюм Насыйри. Кырык вәзир.
30. Рифә Рахман. Бер микъдар былбыл / Сөннәтче әби.
31. Шамил Рәкыйпов. Кызлар–йолдызлар.
32. Сәгыйть Рәмиев. Сызла, күңелем! (җыентык)
33. Габделхәй Сабитов. Хикәяләр.
34. Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр (җыентык).
35. Хәсән Туфан. Кайсыгызның кулы җылы? (җыентык)
36. Равил Фәйзуллин. Якты моң / Җил – вакыт ул (җыентыклар).
37. Сибгат Хәким. Сусау (җыентык).
38. Халык иҗаты: риваять һәм легендалар.
39. Халык иҗаты: эпос-дастаннар.
40. Халык иҗаты: бәетләр һәм мөнәҗәтләр.

**Өлкән сыйныф укучылары өчен**

41. Гариф Ахунов. Чикләвек төше / Идел кызы.
42. Мөдәррис Әгъләм. Кан тамырын кистем (җыентык).
43. Рәшит Әхмәтҗанов. Ачлык мәйданы (җыентык).
44. Роберт Әхмәтҗан. Таш аргамак (җыентык).
45. Харрас Әюп. Йөз яктысы (җыентык).
46. Рабит Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк / Сөембикә.
47. Салих Баттал. Олы юл буйлап / Чирмешән якларында.
48. Әхсән Баян. Яшьлегемне эзлим / Урланган ай.
49. Гомәр Бәширов. Җидегән чишмә.
50. Хәй Вахит. Туй алдыннан.
51. Разил Вәлиев. Мирас / Кояшлы җыр.
52. Марсель Галиев. Нигез / Ак абагалар.
53. Тәлгат Галиуллин. Сәет Сакманов.
54. Наис Гамбәр. Ачык калган тәрәзәм… (җыентык)
55. Рәдиф Гаташ. Гөлләр су сорый (җыентык).
56. Таҗи Гыйззәт. Чаткылар / Ташкыннар.
57. Аяз Гыйләҗев. Яра / Балта кем кулында? / Йәгез, бер дога…
58. Муса Җәлил. Моабит дәфтәрләре.
59. Ркаил Зәйдулла. Мәгарә / Ил (җыентыклар).
60. Зөлфәт. Йөрәгемне былбыл чакты (җыентык).
61. Галимҗан Ибраһимов. Адәмнәр.
62. Гаяз Исхакый. Зөләйха / Олуг Мөхәммәд.
63. Хисам Камал. Үлгәннән соң яздым.

**“Яшә китап”акциясе**

2-3 сыйныф укучылары китапханәдәге китапларны дәваладылар.Алар бу акциядә ярдәмгә мохтаж булган 28 китапны дәвалады.



**Октябрь –Халыкара мәктәп китапханәчеләре айлыгы**

“Октябрь ае- халыкара мәктәп китапханәләре айлыгы” дип игълан ителде.

Айлыкның беренче көннәрендә 1 сыйныф укучылары китапханәбездә экскурсиядә булды.Укучыларны китапханәче Алсу Зөфәр кызы каршы алды. Китапханәдән бөркелгән нур һәм җылылык барлык укучыларны да үзенә тартып тора иде.

Айлык барышында 4 сыйныф укучылары белән “Борынгы китаплар тарихы ” исем астында библиографик дәрес үткәрде. Бу дәрестә укучыларны китапханәче китапның барлыкка килу тарихы белән таныштырды. Беренче китаплар кайда һәм нинди материаллардан эшләнгәнен белделәр.

9 сыйныф укучылары дәреслекләрнең сакланышы буенча рейд уздырдылар. Дәреслекләрне дөрес сакламаган укучыларга кисәтү ясалды.



22 июльдән республикабызда **"Китапка икенче тормыш бүләк ит"** дип аталган хәйрия акциясе башланды. Әлеге чара кысаларында һәркем үзендә булган яхшы хәлдәге кызыклы китаплар, дәреслекләрне мәктәп китапханәләренә тапшыра ала. Безнең мәктәпнең укучылыры да бу акциядән читтә калмады. Бигрәк тә 2,3,10 сыйныф укучылары актив катнашты.









**Татарстанның 100 еллыгына багышланган китап күргәзмәсе**

64. Шәриф Камал. Курай тавышы / Чит илдә.
65. Камил Кәримов. Ком сәгате.
66. Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр (җыентык).
67. Флүс Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет / Хыянәт.
68. Мәдинә Маликова. Шәфкать.
69. Зиннур Мансуров. Җәрәхәтле йөрәк җылырак (җыентык).
70. Мөхәммәт Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә / Фронтовиклар / Ачы тәҗрибә.
71. Туфан Миңнуллин. Ай булмаса, йолдыз бар / Әниләр һәм бәбиләр.
72. Фәрваз Миңнуллин. Балта явызлар кулында (мәкаләләр җыентыгы
73. Мөхәммәт Мирза. Тере су (җыентык).
74. Газинур Морат. Түбә (җыентык).
75. Рафаэль Мостафин. Өзелгән җыр эзеннән.
76. Ринат Мөхәммәдиев. Сират күпере.
77. Җәмит Рәхимов. Батырша.
78. Әхмәт Рәшит. Сөембикә / Колшәриф.
79. Фоат Садриев. Кыргый алма әчесе.
80. Хәсән Сарьян. Бер ананың биш улы.
81. Факил Сафин. Гөлҗиһан / Биек тауның башларында.
82. Кадыйр Сибгатуллин. Әйтте шагыйрь (җыентык).
83. Саҗидә Сөләйманова. Тормыш, исәнме!
84. Гурий Тавлин. Афәт.
85. Һади Такташ. Мәхәббәт тәүбәсе (җыентык).
86. Кәрим Тинчурин. Зәңгәр шәл.
87. Рафаил Төхфәтуллин. Йолдызым.
88. Нурихан Фәттах. Кырык дүртнең май аенда / Кичү.
89. Ренат Харис. Чехов базары / Исемсезләр.
90. Мөсәгыйть Хәбибуллин. Сөембикә-ханбикә һәм Иван Грозный / Атилла.
91. Зөлфәт Хәким. Гасыр моңы.
92. Айдар Хәлим. Сагыш китабы…/ Өч аяклы ат.
93. Шәриф Хәсәенов. Зөбәйдә – адәм баласы / Мәхәббәт сагышы.
94. Фатих Хөсни. Авыл өстендә йолдызлар / Чыбыркы.
95. Зиннур Хөсняр. Кышлаган үгез / Кичү/ Трагедиягә өч билет.
96. Лена Шагыйрьҗан. Бөҗра вә Хөҗрә (җыентык).
97. Фаил Шәфигуллин. Ак маңгайлы бүреләр / Өй салуның ние бар.
98. Илдар Юзеев. Мәхәббәт китабы / Сандугачлар килгән безгә.
99. Миргазиян Юныс. Табу һәм югалту / Юлда уйланулар.
100. Фәнис Яруллин. Кыйгак-кыйгак каз кычкыра / Кайту.



**Көз — рәссам**

Менә без көткән алтын көз
Урманга килеп җитте.
Агачларның яфракларын
Сарыга буяп үтте.

Миләш кызыл мәрҗән киде,
Каен — алтын күлмәген.
Һәммәсе дә яраттылар
Юмарт көзнең бүләген.

Көз агачларны буяды,
Киендерде, бизәде.
Көзгә рәхмәт әйтеп урман
Чуар яулык изәде.

**“Китап укучы гаилә”**
фотобәйгесе





**Тизәйткечләр**



Абагага бага-бага, башым бәрдем баганага. Андый төймә Ләбибәдә дә бар, Нәфидәдә дә бар.\

Талга кунар бер тартар, Ул тартарны тал тартыр,

Тартар басып талны тартыр,

Тал тартыр, тартар калкыр, Тартар калкыр, тал тартыр.

Тәкәрлек, тәкәрлек, Тәңкәң булса миңа бир.

**Көзге сынамышлар**

Кояш баткадна аяз булып, төньяктан салкынча җил булса, кырау төшәр.

************************

Көз озын килсә, яз да соң килер.

************************

Көзге көн бәс тотса, аязлыкка галәмәт.

**********************

Көзнең ахырында түгәрәк-түгәрәк вак кына боз яуса, кыш суык булыр.

**********************

Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә.

**********************

Суганның кабыгы ике кат булган елны кыш җылы булыр, ә кабыгы күп катлы булган елны кыш салкын булыр.

************************

Урманда чикләвек күп булса, кыш кырыс булачак.

************************

Чия яфраклары коелып бетми торып, күпме генә кар яуса да барыбер эреп бетә.

*************************

**Сәламәт булу өчен**



1.Үзеңә һәм барлык кешеләргә дә Яхшылык, Матурлык, Сәламәтлек телә. Ышаныч, Өмет һәм Мәхәббәт бу изге гамәлдә ярдәмчеләрең булсын.

2. Әтиеңне һәм әниеңне ярат. Үз тормышыңа һәм үзеңнең туганнарың, якыннарың һәм дусларың тормышына шатлан.

3. Һәрнәрсәдә: хезмәттә, ял итүдә, тукланууда чама хисен онытма. Һәрнәрсәдә чаманы белү – сәламәтлек билгесе.

4. Үзеңә һәм үзеңнең якын кешеләреңә алкоголь, тәмәке һәм наркотиклар куллануудан баш тартырга ярдәм ит – алар кешене харап итә. Акылыңны психик агулардан: усаллыктан, көнчелектән, комсызлыктан азат ит.

5. Кешеләргә елмаю бүләк ит. Елмаю – арыган кешеләргә ял, кәеф күтәренкелеге бирә, күңелсезлекләрдән һәм стресслардан арындыра.

6. Хис – тойгыларыңны, ачуыңны тыя бел. Белемең белән горурлан.

7. Үз-үзеңә һәрвакыт: мин булдырам, мин телим, мин кешечә яшәргә тиеш, дип әйт.

8. Һәрчак бер нәрсәне исеңдә тот: ни чәчсәң – шуны урырсың. Кешенең язмышы – үз кулында.

9. Шуны онытма! Сәламәтлек – ул әле барысы да түгел, әмма сәламәтлектән башка барысы да берни түгел. Сәламәтлек – физик көч булудан тыш, рухи шәфкатьлелек тә.

**Редакция адресы:** 423315, ТР, Азнакай районы, Сарлы авылы, Мәктәп урамы, 2 , мәктәп китапханәсе, “Белем чишмәсе” гәҗите
Тираж: 20 экз. Формат: А4